**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 29 октябрендәге 3748 номерлы карары**

**2023 елның 30 ноябрендәге 3742 номерлы**
**Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән расланган**
**Казан шәһәренең Киров районында Мулланур Вахитов, Зур Крыловка, Шоссе урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, вәкаләтле Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023, 2024 һәм 2025 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. 2023 елның 30 ноябрендәге 3742 номерлы Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән расланган Казан шәһәренең Киров районында Мулланур Вахитов, Зур Крыловка, Шоссе урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектының аерым өлешләрен раслау юлы белән үзгәрешләр кертергә

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат органнарының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 29 ноябрендәге
3748 номерлы карарына
кушымта

**2023 елның 30 ноябрендәге 3742 номерлы Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән расланган Казан шәһәренең Киров районында Мулланур Вахитов, Зур Крыловка, Шоссе урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләр**

1. Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләрнең 1 номерлы кушымтасы нигезендә редакциялэп бирергә;

2. Планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләре сызымы фрагментын әлеге үзгәрешләрнең 2 номерлы кушымтасы нигезендә редакциялэп бирергә;

3. Кызыл линияләр сызымының фрагментын, әлеге үзгәрешләргә 4 номерлы кушымта нигезендә билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге кушымтасы белән тулыландырып, әлеге үзгәрешләргә 3 номерлы кушымта нигезендә редакциялэп бирергә;

4. IV «Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмә» бүлегендә:

4.1. 1 пунктта:

4.1.1. икенче абзацта «16,37» саннарын «15,20» саннарына алмаштырырга;

4.1.2. 1.1 таблицаны астөшермә белән түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.1 таблица

**Территориядән файдаланунын проект балансы**

| **Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зона атамасы*** | **Мәйданы, га** | **Мәйдан өлеше, %** |
|---|---|---|
| Күпкатлы торак төзелеше | 6,64 | 43.68 |
| Мәктәпкәчә, башлангыч һәм урта гомуми белем бирү | 3,62 | 23,82 |
| Төзекләндерү | 1.74 | 11.45 |
| Гомуми файдаланудагы яшел үсентеләр | 1.39 | 9.14 |
| Урам-юл челтәре, коммуналь инфраструктура | 1,59 | 10,46 |
| Урам-юл челтәре | 0,22 | 1,45 |
| Барлыгы | 15,20 | 100,0 |

*Шул исәптән капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрендә гамәлдәге законнар нигезендә эшләү өчен кирәкле башка билгеләнештәге объектлар»;

4.1.3. 1.2 таблицаны астөшермә белән түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.2 таблица

**Күпкатлы торак төзелешенең капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зонасы объектлары характеристикалары**

| **Капиталь төзелеш объектларына характеристикалар** | **Торак комплексы һәм планлаштыру структурасы элементлары буенча (кварталлар) күрсәткече** | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Кварталның билгеләнеше | К-1 | | | К-3 | К-2 | | Барлыгы (гомуми күрсәткечләр) |
| Торак комплекс номеры | ЖК-1 | ЖК-2 | ЖК-3 | ЖК-4 | ЖК-5 | ЖК-6 | |
| Күпкатлы торак төзелеше зонасы мәйданы, гектар | 0,45 | 1,37 | 1,59 | 1,19 | 0,40 | 1,64 | 6,64 |
| Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зонасы чикләрендә торак фондының тыгызлыгы, мең кв.м/га | 20,5 | 20,4 | 20,4 | 23,5 | 24,1 | 20,4 | 21,2 |
| Фатирларның гомуми мәйданы, кв.м | 6240 | 26600 | 30225 | 26000 | 9000 | 31200 | 129265 |
| Торак булмаган билгеләнештәге эчкә кертеп-кушып төзелгән биналарның гомуми мәйданы, кв.м | 3000 | 1300 | 2200 | 1950 | 650 | 2200 | 11300 |
| Торак йортлар катларының максималь саны, кат | 22 | 22 | 24 | 23 | 23 | 22 | 24 |
| Планлаштырылган кеше саны, кеше | 208 | 887 | 1007 | 867 | 300 | 1040 | 4309 |

* Капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зонасы өчен торак фондының тыгызлыгы, мең кв.м/га. Территорияне планлаштыру проекты территориясе үзгәртеп төзеләторган территория булуын исәпкә алып, төзелешнең максималь тыгызлыгын 20 процентан арттыру мөмкин түгел»;

4.1.4. 1.3 таблицаны искәрмәләр белән түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.3 таблица

**Күпкатлы торак төзелеше объектларын план буенча урнаштыру зонасы өчен исәп күрсәткечләре**

| **Капиталь төзелеш объектларына** | **Торак комплексының билгеләнеше** | **Барлыгы (гомуми** |
|---|---|---|

| характеристикалар | ЖК-1 | ЖК-2 | ЖК-3 | ЖК-4 | ЖК-5 | ЖК-6 | күрсәтке чләр) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, урыннар | 17 | 72 | 82 | 70 | 24 | 84 | 349 |
| Гомуми белем бирү учреждениеләре, урыннар | 36 | 152 | 172 | 148 | 51 | 178 | 737 |
| Поликлиникалар, бер сменага килүчеләр саны | 4 | 17 | 20 | 17 | 6 | 20 | 84 |
| Торак йортларда яшәүчеләрнең автомобильләрен даими саклау өчен автомобиль кую урыннары, машина урыны | 63 | 266 | 303 | 260 | 90 | 312 | 1294 |
| Торак йортларга килүчеләр өчен автомобиль кую урыннары, машина урыны | 12 | 48 | 54 | 47 | 17 | 56 | 234 |
| Йорт эченә кертеп-кушып төзелгән бүлмәләр өчен автомобиль кую урыннары, машина урыны | 38 | 17 | 28 | 25 | 9 | 28 | 145 |
| Электр энергиясен җыю станцияләре белән тәэмин ителгән автомобильләр кую урыннары, машина урыннары | 1 | 3 | 4 | 3 | 1 | 4 | 16 |

Искәрмәләр:

1. Исәпләүләр буенча автомобильләрне даими саклау өчен урыннар санына булган ихтыяҗ Казан шәһәр округының шәһәр төзелешен проектлау буенча җирле нормативлары нигезендә үзгәртеп төзелә торган территорияне исәпкә алып киметелде.
2. Күрсәткечләр (фатирларның мәйданы, торак булмаган урыннарның мәйданы) киметелгән очракта, парковка урыннарына һәм инфраструктураның башка объектларына булган ихтыяҗ күрсәткечләре шәһәр төзелешен проектлау буенча җирле нормативлар таләпләреннән чыгып яңадан исәпләнә»;

4.2. 2 пунктта:

4.2.1. 2.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.1. Төзелешне җайга салу линиясе, капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзү, реконструкцияләүнең чик параметрлары.

Төзүне җайга салу линияләре (капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зоналары өчен кызыл линияләрдән чигенүләр) капиталь төзелеш объектларын план буенча урнаштыру зонасы чикләре сызымында чагылдырылган, инженерлык инфраструктурасы объектларын урнаштыруга комачауламый.

Капиталь төзелеш объектларын проектлаганда инженерлык ягыннан тәэмин итү объектларыннан һәм челтәрләреннән минималь ераклыкны исәпкә алырга кирәк.

ЖК-1, ЖК-4, ЖК-5 чикләрендәге җир кишәрлекләре өчен капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең түбәндәге чик параметрлары билгеләнә:

- инженерлык ягыннан тәэмин итү объектларыннан минималь ераклыкларны саклау шарты белән җир кишәрлекләре чикләреннән минималь чигенүләр нульгә тигез; сызымда кызыл линияләр белән туры килми торган җайга салу линияләре булган җир кишәрлекләре чикләреннән минималь чигенешләр төзүне җайга салу линияләре буенча билгеләнә;

- җир кишәрлеген яшелләндерүнең минималь проценты, торак төзүнең иҗтимагый яшелләндерелгән территорияләргә кушылуына бәйле рәвештә, 50% ка кыскартуны исәпкә алып, шәһәр төзелеше регламенты нигезендә исәпләнә;

- җир кишәрлеген төзүнең (торак фондының) максималь тыгызлыгы – ЖК-1 өчен – 28,0 мең кв. м/га, ЖК-4 өчен – 24,9 мең кв. м/га, ЖК-5 өчен – 24, 1 мең кв. м/га;

4.2.2. 2.2 пунктчасының 2.1 таблицасында «1224 урын» сүзләрен «1501 урын» сүзләренә алмаштырырга;

4.2.3. 2.3 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ЖК-1 өчен җир кишәрлеге чикләрендә 89 парковка урыны урнаштырыла һәм аерым җир кишәрлегендә җәяү барып җитәрлек 500 м чикләрдә – 25 парковка урыны урнаштырыла»;


4.2.4. 2.5 пунктчада «3,22» саннарын «3,13» саннарына алмаштырырга.

5. «Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә» дигән V бүлектә:

5.1. «Төзелеш этаплары» сүзләрен, астөшермәле таблицаны төшереп калдырырга;

5.2. 1 нче схеманы түбәндәге редакциядә бирергә:

«1 нче схема




»;

5.3. «Территорияне планлаштыру проектын раслауга бәйле рәвештә тартып алынырга (резервланырга) тиешле җир кишәрлекләре исемлеге» пунктын гамәлдән чыгарырга.

5.4. бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2 нче таблица өстәргә:

«2 таблица

**Чараларны гамәлгә ашыруның этаплары һәм максималь сроклары**


<table>
<tr><th rowspan="2">Капиталь төзелеш объектлары төрләре</th><th rowspan="2">Объектлар</th><th colspan="3">Максималь сроклар, ел</th></tr>
<tr><th>.<br>Архитектура-төзелеш ягыннан проектлаштыру (җир кишәрлеге ясау/архитектура ягыннан проектлаштыру /экспертиза)</th><th>Төзелеш</th><th>Төзелеш территориясендә урнашкан гамәлдәге объектларны сүтү</th></tr>
<tr><td rowspan="2">Социаль инфраструктура</td><td>140 урынга исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү оешмасы</td><td rowspan="5">2030</td><td rowspan="2">2034**</td><td rowspan="5">-</td></tr>
<tr><td>1501 урынга исәпләнгән гомуми белем бирү оешмасы</td></tr>
<tr><td>Инженерлык инфраструктурасы</td><td>Инженерлык инфраструктурасы объектлары</td><td>2030</td></tr>
<tr><td>Транспорт инфраструктурасы</td><td>Бугринская урамы, 1 нче юл, 2 нче юл.<br>1 нче юл төзелгәнче, Вахитов урамыннан ЖК-1 квартал эчендәге юлга вакытлыча керү оештырыла</td><td>2034</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Торак билгеләнешендәге</td><td>11300 кв. м гомуми мәйданлы торак булмаган билгеләнештәге кертеп төзелгән биналар урнаштырылган, фатирларның гомуми мәйданы 129265 кв. м булган күпфатирлы торак йортлар</td><td>2034*</td></tr>
<tr><td>Планлаштырыла торган төзү участокларында шәхси торак йортлар</td><td>-</td><td>-</td><td>2034</td></tr>
</table>

* төзелешкә рөхсәттә төгәлләштерелергә мөмкин;


** дәүләт һәм муниципаль программаларны формалаштыру срокларын исәпкә алып төгәлләштерелергә мөмкин».

___

2023 елның 30 ноябрендәге 3742
номерлы Казан шәһәре
Башкарма комитеты карары
белән расланган Казан
шәһәренең Киров районында
Мулланур Вахитов, Зур
Крыловка, Шоссе урамнары
белән чикләнгән территорияне
планлаштыру проектына кертелә
торган үзгәрешләргә
1 номерлы кушымта



2023 елның 30 ноябрендәге 3742 номерлы Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән расланган Казан шәһәренең Киров районында Мулланур Вахитов, Зур Крыловка, Шоссе урамнары белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектына кертелә торган үзгәрешләргә
2 номерлы кушымта



2023 елның 30 ноябрендәге 3742
номерлы Казан шәһәре
Башкарма комитеты карары
белән расланган Казан
шәһәренең Киров районында
Мулланур Вахитов, Зур
Крыловка, Шоссе урамнары
белән чикләнгән территорияне
планлаштыру проектына кертелә
торган үзгәрешләргә
3 номерлы кушымта

